**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 42 статьясы һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында» 2023 елның 4 февралендәге ПУ-68 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы функцияләрен йөкләргә.

2. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында нигезләмәне кушымта нигезендә расларга.

3. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты турында» 2005 елның 22 декабрендәге ПУ-512 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2013 елның 26 июлендәге ПУ-693 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 1 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәткәрләре эшләре департаменты турында» Татарстан Республикасы Президенты Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 28 февралендәге ПУ-233 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының коррупциягә каршы сәясәтен гамәлгә ашыру өлкәсендә эшчәнлекне камилләштерү чаралары турында» 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 1 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен һөнәри яктан үстерү буенча чараларга дәүләт заказы турында» 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-252 номерлы Указының 2 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Президентының аерым актлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 17 декабрендәге ПУ-889 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 4 пункты;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре турындагы аерым указларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 20 декабрендәге ПУ-905 номерлы Указына кушымтада бирелгән Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлегенең 1 пункты.

4. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 19 июнь
№ 411

Татарстан Республикасы
Рәисенең
2023 елның «19» июнендәге
411 номерлы Указы белән
расланды

**Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты турында**
**нигезләмә**

I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты (алга таба – Департамент) Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте (алга таба шулай ук – дәүләт хезмәте) өлкәсендә кадрлар сәясәтен, дәүләт сәясәтен уздыру буенча вәкаләтләрен башкаруын, шулай ук законнарда каралган очракларда – Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт өлкәсендәге вәкаләтләрен башкаруын тәэмин итү максатларында төзелде.

2. Департамент Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенә идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы функцияләрен башкара һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәсе булып тора.

3. Департамент үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, Татарстан Республикасы Конституциясенә, федераль конституциячел законнарга, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасының башка законнарына, Татарстан Республикасы Рәисе указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе турында нигезләмәгә, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе боерыкларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

4. Департамент Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә буйсына.

5. Департамент турында нигезләмә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннанраслана.

## II. Департаментның төп бурычлары

6. Департаментның төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

Татарстан Республикасы Рәисенә дәүләт хезмәтен реформалау һәм үстерү буенча төп юнәлешләрне билгеләүдә, әлеге мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнарының килешенгән эшчәнлеген һәм хезмәттәшлеген тәэмин итүдә булышлык күрсәтү;

үз компетенцияләре чикләрендә дәүләт хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең үзара бәйләнешен тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы Рәисенә дәүләт хезмәте һәм кадрлар сәясәте мәсьәләләренә кагылышлы тәкъдимнәр әзерләү;

дәүләт хезмәтен һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтне нәтиҗәле узуны тәэмин итү;

үз компетенцияләре чикләрендә дәүләт хезмәте турындагы законнарның, Татарстан Республикасы Рәисенең дәүләт хезмәте һәм кадрлар мәсьәләләре буенча указлары, боерыклары һәм йөкләмәләренең үтәлешен контрольдә тоту;

дәүләт хезмәтенең кадрлар составын исәпкә алу һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составын исәпкә алуда булышлык итү;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең (алга таба тиешенчә – дәүләт хезмәткәрләре һәм муниципаль хезмәткәрләр) һөнәри үсеше системасын камилләштерү;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары кадрлар хезмәтләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү өлешендә коррупциягә каршы көрәшүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе эшчәнлеген кадрлар һәм оештыру-штат ягыннан тәэмин итү.

## III. Департаментның төп функцияләре

7. Департаментның төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары проектларын әзерләүдә катнашу;

Татарстан Республикасы Конституциясендә каралган вазыйфаларга билгеләп кую һәм әлеге вазыйфалардан азат итү турында Татарстан Республикасы Рәисе актлары проектларын әзерләү;

Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына еллык юлламалары өчен дәүләт хезмәте мәсьәләләренә кагылышлы материаллар әзерләүдә катнашу;

дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча законнарны куллану практикасын анализлау, Татарстан Республикасы

Рәисенә дәүләт хезмәтен реформалау һәм камилләштерү мәсьәләләре буенча аналитик һәм мәгълүмати материаллар әзерләү;

өлге буларак куллану өчен дәүләт хезмәткәрләренең вазыйфаи регламентларын раслау;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарында биләнә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын дәүләт хезмәте вазыйфалары категорияләренә кертүне килештерү;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарында дәүләт хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә законнар таләпләре үтәлүен контрольдә тотуны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары кадрлар хезмәтләренең дәүләт хезмәте һәм коррупциягә каршы көрәшү турындагы законнарның үтәлеше мәсьәләләренә кагылышлы эшчәнлеген координацияләүне һәм контрольдә тотуны тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының кадрлар хезмәтләренә методик ярдәм һәм консультация ярдәме күрсәтү;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә кадрлар резервына кертү өчен үткәрелә торган конкурсларда, дәүләт хезмәткәрләрен аттестацияләүне уздыруда катнашу;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарының конкурс, аттестация комиссияләре составларына кертелә торган бәйсез экспертлар реестрын формалаштыру һәм алып бару, белән үзара эшчәнлекне оештыру;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәте вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнарның яисә дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдә катнашу;

дәүләт һәм муниципаль хезмәт өчен квалификацияле кадрлар җәлеп итүгә юнәлдерелгән чаралар уздыруда катнашу;

дәүләт хезмәткәрләрен кызыксындыру һәм аларның һөнәри хезмәт эшчәнлеген бәяләүнең яңа ысулларын эшләү һәм кулланышка кертү;

Татарстан Республикасы Рәисе яисә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе йөкләмәләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнарының структур һәм штат расписаниеләрен эшләүдә катнашу;

дәүләт хезмәткәрләрен ротацияләүне уздыруда катнашу;

дәүләт хезмәтендә остазлык һәм яңа шартларга җайлашу системасының эшләвен оештыру;

дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри яктан әзерлеген яхшыртуга юнәлтелгән нәтиҗәле технологияләр һәм кадрлар белән эшләүнең заманча ысулларын эшләү һәм кулланышка кертү, эшчәнлекнең нәтиҗәлелеген арттыру өчен шартлар тәэмин итү;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан дәүләт хезмәте стажын дөрес итеп санау һәм билгеләүгә методик җитәкчелек һәм контрольлек итү;

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәтенең кадрлар составына идарә итүнең бердәм мәгълүмат системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшен мониторинглау һәм методик ярдәм күрсәтү;

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында кадрлар эшен алып баруны методологик яктан тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисенең «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында дәүләт хезмәтен үстерү турындагы актуаль мәкаләләрне һәм мәгълүматларны урнаштыруга әзерләү;

дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы көрәшү мәсьәләләре буенча дәреслекләр, фәнни-методик әдәбият, мәгълүмати материалларны һәм башка басма продукцияне әзерләүдә катнашу;

дәүләт хезмәте һәм муниципаль хезмәтнең абруен күтәрүгә, яшьләр арасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтне популярлаштыруга юнәлтелгән чараларда катнашу;

законнарда билгеләнгән тәртиптә гражданнарга һәм оешмаларга Департамент компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча консультация ярдәме күрсәтү;

дәүләт хезмәткәрләренә диспансеризация үткәрүне оештыруда катнашу;

Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затларны исәпкә алуны алып бару;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарының кадрлар составын исәпкә алуны оештыру;

тиешле җирле үзидарә органнары белән килештереп, муниципаль хезмәткәрләр турында мәгълүматларны туплау һәм исәпкә алу;

законнарда билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның җитәкче составы турындагы мәгълүматларны исәпкә алу;

дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт таныклыклары бланкларын исәпкә алу һәм саклау, шулай ук дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт таныклыкларын юкка чыгару тәртибен раслау;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары биләүче затларның таныклыклары бланкларын исәпкә алу һәм саклау, шулай ук әлеге затларның таныкларын юкка чыгару тәртибен эшләү һәм раслау;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы кадрлар резервын формалаштыру, Татарстан Республикасы кадрлар резервы белән эшләүне, аннан нәтиҗәле файдалануны оештыру;

Татарстан Республикасы идарәче кадрлары резервын формалаштыру, әзерләү һәм алардан нәтиҗәле файдалануны буенча эшне оештыру;

федераль дәүләт органнары таләпләре һәм тәкъдимнәрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары заявкалары нигезендә, Татарстан Республикасы икътисады ихтыяҗларын күздә тотып, һөнәри үсеш юнәлешләрен эшләү;

дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри үсеше буенча еллык календарь план проектын формалаштыру;

дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше буенча чараларга дәүләт заказын формалаштыру;

дәүләт хезмәте өчен кадрлар әзерләүне координацияләү;

җирле үзидарә органнарына муниципаль хезмәткәрләргә өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру мәсьәләләре буенча булышлык итү;

дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсеше шәхси планнарын үз вакытында актуальләштерүне һәм аларның Татарстан Республикасы дәүләт органнарында гамәлгә ашырылуын контрольдә тотуны тәэмин итү;

һөнәри үсеш чараларының, шул исәптән дәүләт хезмәткәрләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең квалификациясен күтәрү һәм аларны һөнәри яктан яңадан әзерләү программаларының тормышка ашырылу сыйфатын бәяләү индикаторларын билгеләү;

Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфалары, муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга өстәмә һөнәри белем бирү программаларын тормышка ашыруда катнашу;

Татарстан Республикасы Рәисенә Татарстан Республикасы идарәче кадрларны сайлау буенча тәкъдимнәр әзерләү;

законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт хезмәтенең югары төркеме вазыйфаларын биләүче затларны эшкә алу һәм эштән азат итү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр бирү;

законнарда билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын, Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләре вазыйфаларын биләүче затларның таныклыкларын, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куелган дәүләт хезмәткәрләренең хезмәт таныклыкларын рәсмиләштерү;

билгеләнгән тәртиптә «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында билгеләнгән очракларда Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең классны чиннарын бирү турында Татарстан Республикасы Рәисе указлары проектларын әзерләү;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнарның керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрен, әлеге дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләрен кабул итү, анализлау һәм тикшерү, шулай ук әлеге дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт

хезмәткәрләренең законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләрне үтәвен тикшерү;

Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче затларның һәм аларның Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтеннән азат ителгәннән соң федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган очракларда хезмәт шартнамәсен һәм (яисә) гражданлык-хокукый шартнамәсен үтәүләре турында белешмәләрне анализлау;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары кадрлар хезмәтләре җитәкчеләре вазыйфаларына кандидатураларны карап тикшерүдә катнашу;

дәүләт хезмәтенең, Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең үсешен, Татарстан Республикасы дәүләт органнарында кадрлар белән бәйле вазгыятьне мониторинглау;

Татарстан Республикасы дәүләт органнарында хезмәт культурасын үстерү буенча тәкъдимнәр эшләү һәм эшчәнлекне координацияләү;

Татарстан Республикасы Рәисе Эшләр идарәсе белән берлектә Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Кадрлар сәясәте мәсьәләләре буенча совет эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе структурасын камилләштерү буенча тәкъдимнәр бирү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә дәүләт хезмәтенә керү, аны узу, хезмәт контракты төзү, дәүләт хезмәте вазыйфасына билгеләп кую һәм биләгән дәүләт хезмәте вазыйфасыннан азат итү, дәүләт хезмәткәрләрен дәүләт хезмәтеннән чыгару һәм аларның тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгулары белән бәйле Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе актлары проектларын әзерләү һәм тиешле карарларны рәсмиләштерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт хезмәте вазыйфалары булмаган вазыйфаларны биләүче хезмәткәрләрне Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенә эшкә алу, алар белән хезмәт шартнамәләре төзү, аларны эштән азат итү белән бәйле акт проектларын әзерләү һәм тиешле карарларны рәсмиләштерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт хезмәткәрләре реестрын алып бару;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә дәүләт хезмәтенең вакантлы вазыйфаларын биләүгә, кадрлар резервына кертүгә конкурсларны, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең дәүләт хезмәткәрләрен аттестацияләүне, дәүләт хезмәтенә алганда аларга сынау уздыруны оештыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә хезмәт тәртибен үтәүне контрольдә тотуны оештыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренең вазыйфаи үсешен тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә кадрлар резервын формалаштыру, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең кадрлар резервы белән эшләүне һәм аны нәтиҗәле файдалануны оештыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә куелган таләпләрне үтәве һәм мәнфәгатьләр каршылыкларын җайга салу буенча комиссия эшчәнлеген тәэмин итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе дәүләт хезмәткәрләрендә дәүләт хезмәтендә мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә этәргеч бирүче сәбәпләр һәм шартларны ачыклау һәм бетерү буенча чаралар күрү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренә дәүләт хезмәтенә кагылышлы хокукый мәсьәләләр һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирү;

гражданның Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә дәүләт хезмәтенә алынганда биргән шәхси һәм башка төрле белешмәләрнең дөреслеккә туры килү-килмәвен тикшерүне оештыру, шулай ук дәүләт сере булган мәгълүматлар белән эшләү өчен билгеләнгән формада рөхсәт кәгазен рәсмиләштерү өчен документлар әзерләүдә катнашу;

эш урынында тикшерүләр уздыруны оештыру, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләре тарафыннан хезмәт дисциплинасын үтәмәү очракларын һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм аның хезмәткәрләре арасында туган хезмәт бәхәсләрен карап тикшерүдә катнашу;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе дәүләт хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләрен кабул итү, анализлау һәм тикшерү, шулай ук коррупциягә каршы көрәшү максатларында аларның законнар нигезендә билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, таләпләрне үтәвен тикшерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе дәүләт хезмәткәрләренең һөнәри үсешен оештыру;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренә ел саен бирелә торган ял графикларын төзү һәм аларның үтәлешенә контрольлек итү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренә ел саен бирелә торган һәм башка төрле ялларны рәсмиләштерү;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренең хезмәт командировкаларын рәсмиләштерү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренең шәхси документлары тупланмасын һәм хезмәт кенәгәләрен (булган очракта)

алып бару, аларның Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясендә хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне формалаштыру һәм әлеге белешмәләрне Россия Федерациясенең мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе системасында шәхси (персоналаштырылган) исәпкә алуны алып бару турында законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия һәм социаль иминият фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен бирү;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләренең хезмәт таныклыкларын рәсмиләштерү һәм бирү;

Департамент компетенциягә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе хезмәткәрләре өчен мәгълүмати материаллар әзерләү һәм юллау.

Департамент Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча башка функцияләрне башкара.

## IV. Департаментның хокуклары

8. Департамент үзенең бурычларын һәм функцияләрен башкарганда түбәндәгеләргә хокуклы:

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең структур бүлекчәләреннән, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппаратыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратыннан, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнарыннан, федераль дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, шулай ук оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан тиешле мәгълүмат һәм материалларны соратып алырга;

үз компетенциясе чикләрендә Татарстан Республикасы дәүләт органнарының дәүләт хезмәте турында законнар таләпләренең үтәвенә тикшерү уздырырга;

билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасының дәүләт мәгълүмат системаларындагы мәгълүматтан, шулай ук коррупциягә каршы көрәшү өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланырга;

билгеләнгән тәртиптә дәүләт элемтә һәм коммуникация системаларыннан файдаланырга;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән килештереп, Россия Федерациясе законнары нигезендә дәүләт хезмәтен мониторинглау һәм үстерү мәсьәләләре буенча аерым эшләрне башкару өчен фән һәм мәгариф оешмаларын, шулай ук галимнәрне һәм белгечләрне җәлеп итәргә.

9. Департамент Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтенә идарә итү буенча Татарстан Республикасы дәүләт органы функцияләрен башкару максатларында, үз компетенциясе чикләрендә, карарлар рәвешендә хокукый актлар чыгара, аларга Департамент җитәкчесе кул куя.

## V. Департаментның хезмәттәшлек итү даирәсе

10. Департамент үзенә йөкләнгән функцияләрне гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, федераль дәүләт органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектлары дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм вазыйфаи затлар, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясенең барлык структур бүлекчәләре һәм вазыйфаи затлары белән хезмәттәшлек итә.

## VI. Җаваплылык

11. Департамент хезмәткәрләре Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан расланган вазыйфаи регламентлар нигезендә аларга йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була.

## VII. Департамент эшчәнлеген оештыру

12. Департаментның структурасы һәм штат саны Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан раслана.

13. Департамент эшчәнлегенә Татарстан Республикасы Рәисе указы нигезендә вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә торган Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе (алга таба – Департамент җитәкчесе) җитәкчелек итә.

14. Департамент җитәкчесе:

Департамент эшен оештыра, Департаментка йөкләнгән бурычларны үтәү өчен җаваплы була;

Департаментның төп эшчәнлеген планлаштыруны оештыра;

үз компетенцияләре чикләрендә документларга кул куя һәм имза сала;

Департамент хезмәткәрләре арасында вазыйфаи бурычларны бүлә һәм аларның вазыйфаи регламентларын Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә раслауга бирә;

Департаментта яшерен хезмәт языштуы режимын, дәүләт һәм закон тарафыннан саклануучы серне тәшкил иткән, шулай ук таратырга ярамаган хәбәрләрдән торган мәгълүмат белән эшләүне тәэмин итә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе каравына Департаментның структурасы, штат саны, Департамент хезмәткәрләрен вазыйфага билгеләп кую һәм вазыйфадан азат итү турында тәкъдимнәр бирә;

Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесенә Департамент хезмәткәрләрен бүләкләү яисә аларны дисциплинар җәзага тарту турында тәкъдимнәр бирә;

Департамент компетенциягә караган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Рәисе һәм Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе белән фикер алышуларда катнаша;

Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе кушуы буенча Татарстан Республикасы дәүләт органнары уздырган коллегия утырышларында, киңәшмәләрдә катнаша, билгеләнгән тәртиптә Департамент вәкилләрен коллегия утырышларында һәм киңәшмәләрдә катнашырга җибәрә.

15. Департамент җитәкчесе вакытлыча эш урынында булмаган чорда аның вазыйфаларын Департамент җитәкчесе урынбасары – дәүләт хезмәтен үстерү бүлеге мөдире яисә Департаментның башка вәкаләтле вазыйфаи заты башкара.

16. Департамент хезмәткәрләре Департамент җитәкчесе тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе тарафыннан вазыйфага билгеләп куела һәм вазыйфадан азат ителә.